ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 26.02.2026 298 **КАРАР**

2026-2028 елларга Алабуга муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке кулланыну кимету буенча муниципаль программаны раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 9 июлендәге 765 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026-2028 елларга Алабуга муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке кулланыну кимету буенча муниципаль программаны расларга (1 нче кушымта).

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

2.1. «2017-2019 елларга Алабуга муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке кулланыну кимету» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 18 апрелендәге 473 номерлы;

2.2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2019 елларга Алабуга муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке кулланыну кимету» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 18 апрелендәге 473 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 27 декабрендәге 1663 номерлы;

2.3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2021 елларга Алабуга муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке кулланыну кимету»

муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 18 апрелендәге 473 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 23 октябрендәге 990 номерлы;

2.4. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2022 елларга Алабуга муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке кулланыны киметү» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 18 апрелендәге 473 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 ноябрендәге 1546 номерлы.

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) әлеге максатларга билгеләнгән тәртиптә һәм җирле бюджетта каралган ассигнованиеләр чикләрендә программаны финанслауны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 2AE1AA8E107BD0A6911BA308E44A8D0A
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 28.01.2025 до 23.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта

# 2026-2028 елларга Алабуга муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү буенча муниципаль программа

Алабуга, 2026

ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2026-2028 елларга Алабуга муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен төп нигез | «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы;<br>«Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирә тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке куллану нәтиҗәләреннән саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ Федераль закон;<br>Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Тәмәке продукциясен куллануны киметү чаралары турында» 2019 елның 3 сентябрендәге 1760 номерлы боерыгы. |
| Программының заказчысы | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләүчесе | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» сәламәтлек саклау дәүләт автономияле учреждениесе (килешү буенча) |
| Программаны төп башкаручылар | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет), «Алабуга үзәк район хастаханәсе» сәламәтлек саклау дәүләт автономияле учреждениесе (килешү буенча), «АМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ, АМР Башкарма комитетының спортны үстерү секторы, АМР Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторы, «АМР Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ (килешү буенча), массакүләм мәгълүмат чаралары (килешү буенча), ЭЭБ (килешү буенча) |
| Программының максатлары | Сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, культура дәрәҗәсен һәм сәламәтлек потенциалын күтәрү, вакытыннан алда үлү очракларын кисәтү, сәламәт туклану исәбенә сәламәт яшәү рәвеше алып баручы гражданнарның өлешен арттыру, зарарлы гадәтләрдән, алкоголь һәм тәмәке кулланудан баш тарту. Сәламәт яшәүнең көтелгән дәвамлылыгын 67 яшькә кадәр арттыру. |
| Программының бурычлары | 1. Сәламәт туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләү системасын формалаштыру; |



Документ создан в электронной форме. № 298 от 26.02.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 4 из 24. Страница создана: 25.02.2026 11:27

| | |
|---|---|
| | 2. Халыкның төрле яшь төркемнәрендә (шул исәптән эчкечелек, алкоголь психозлары, наркомания һәм токсикоманияне дә кертеп, наркологик авыруларны да кертеп) таралуы һәм авырулар санының киметү;<br>3. Тәмәке тарту һәм хәмер куллануны таратуны киметү;<br>4. Алкогольле продукция, сыра, тәмәке куллануны киметү, эшләүче гражданнарның сәламәтлеген саклау, сәламәтлек культурасын формалаштыру өлкәсендә иҗтимагый сәламәтлекне саклау системасын, физик культура һәм спортны, мәгарифне үстерү;<br>5. Норматив-методик базаны камилләштерү һәм профилактик эшчәнлекне оештыру;<br>6. Халык арасында исерткеч эчемлекләр, сыра һәм тәмәке куллануны киметү буенча оешма, предприятиеләр, һәм учреждениеләр хезмәткәрләрен сәламәт яшәү рәвешәен булдыру максатларыннан, кадрлар белән тәэмин итү һәм укытуны оештыру;<br>7. Алабуга муниципаль районында халык арасында алкогольле продукция, сыра, тәмәке куллануны киметүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга караган укытуның нәтиҗәле методологиясен эшләү. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2026-2028 еллар |
| Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме | Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетын формалаштыруны исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертергә (төгәлләш терелергә) тиеш.<br><br>(мең.сумнарда)<br><br>(see table below) |
| Программаның | Халык арасында алкогольле продукция, сыра, тәмәке |

| Елы | Финанслауның чыгымнары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **Җирле бюджет** | **ТР бюджеты** | **Бюджеттан тыш** | **БАРЛЫГЫ** |
| **2026** | 40 881,3 | 13 812,8 | 3,2 | 54 697,3 |
| **2027** | 42 460,3 | 14 539,8 | 3,2 | 57 003,3 |
| **2028** | 44 102,5 | 14 991,0 | 3,2 | 59 096,7 |
| **Барлыгы** | **127 444,1** | **43 343,6** | **9,6** | **170 797,3** |



Документ создан в электронной форме. № 298 от 26.02.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 5 из 24. Страница создана: 25.02.2026 11:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | |
|---|---|
| көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | куллануны киметүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга карарта төп тормыш күнекмәләрен үстерү;<br>Халыкның үз сәламәтлеге өчен җаваплылыгы дәрәҗәсен арттыру;<br>Халыкның сәламәтлек дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү, үлүчеләр санын, инвалидлыкны киметү;<br>Алкогольле эчемлекләр, тәмәке кулланучы затларның саннарын киметү;<br>Яшь буында югары гомуми культура формалаштырырга мөмкинлек бирә торган сәламәт яшәү рәвешен тәрбияләүнең бербөтен системасын булдыру;<br>яшь буында сәламәт яшәү рәвеше формалаштыруны тәрбияләү;<br>яшүсмер шәхесен әхлакый, интеллектуаль һәм физик формалаштыру өчен уңай шартлар тудыру. |

## I. Программаны тормышка ашыру сферасының гомуми характеристикасы, шул исәптән программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

2026 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкогольле продукция, сыра һәм тәмәке куллануны киметү буенча муниципаль программа сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруның бердәм системасын булдыру, бүгенге һәм киләчәк буыннарның сәламәтлегенең югары дәрәҗәсенә ирешү, халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, кеше потенциалын саклап калу һәм үстерү, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы халкының уртача гомер озынлыгын һәм сыйфатын арттыру белән бәйле рәвештә эшләнде.

Сәламәтлек торышы - ул социаль, психик, икътисадый һәм экологик иминлекнең мөһим күрсәткече, халыкның тормыш сыйфаты билгесе.

Сәламәтлекнең торышына әйләнә-тирә мохитнең һәм җәмгыятьнең иминлеге, торак һәм туклану сыйфаты, тәмәке тарту таралу һәм алкоголь эчемлекләрне куллану, алкоголь эчемлекләрен, шул исәптән сыра сату күләме, тәмәке эшләнмәләрен сатып алу чыгымнары, физик культура белән шөгыльләнү мөмкинлеге, белем һәм керемнәр дәрәҗәсе кебек төрле факторлар йогынты ясый.

Хлыкның сәламәтлек проблемасы социаль-икътисадый характерга ия: беренчедән, халыкның сәламәтлек сыйфаты эшләүче гражданнарның хезмәт җитештерүчәнлегенә турыдан-туры йогынты ясый; икенчедән, эшләмәүче халык саны арту аркасында, эшкә яраклы халыкка эш йөкләмәсе арта, бу социаль киеренкелекнең сәбәбе булып тора һәм керемнәрнең кимүенә, шулай



Документ создан в электронной форме. № 298 от 26.02.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 6 из 24. Страница создана: 25.02.2026 11:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

ук эшләүче кешеләрнең тормыш дәрәҗәсе начараюга итерә. Хәзерге вакытта төп проблемалар:

- туучылар санын арттыру, кан әйләнеше системасы авырулары, туберкулез, яман шешләр, агуланулар, имгәнүләр таралу, шул исәптән юл-транспорт һәлакәтләре вакытында алынган очраклар;

- эчкечелек, алкоголь психозлары, наркомания һәм токсикоманияне дә кертеп, наркологик авырулар булуы, яшьләр арасында асоциаль күренешләр;

- автотранспорт һәм предприятиеләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә атмосфера пычрануы;

- эчкән суларның начар сыйфатлы булуы;

- калдыклар саны арту, аларны утильләштерү һәм эшкәртү зарурилыгы.

Халыкның сәламәтлеген ныгытуга һәм әйләнә-тирә мохитне савыктыруга юнәлдерелгән сәясәт формалаштыру, кешеләрнең үз сәламәтлекләренә һәм тирә-юньдәгеләрнең сәламәтлегенә җаваплы карашын булдыру аша халыкның һәм киләчәк буынының сәламәтлек дәрәҗәсен күтәрергә мөмкин. Районда яшәүчеләрнең сәламәт яшәү рәвеше алып баруы үлүчеләр саны кимүгә, шул исәптән хезмәткә яраклы халык арасында, төрле яшь төркемнәрендә, өлкәннәр арасында да, балалар арасында да авырулар санының кимүенә, инвалидлык буенча пенсиягә вакытыннан алда чыгу очракларының кимүенә, авыруларны кисәтүгә һәм башлангыч стадияләрдә ачыклауга йогынты ясаячак. Сәламәт яшәү рәвеше, сәламәтлек саклау өлкәсендәге югары күрсәткечләр үлүчеләр саны кимүгә һәм туучылар саны артуга китерәчәк, бу районда демографик вәзгыятькә уңай йогынты ясаячак. 1975 елда ук БМОның Генераль ассамблеясе тарафыннан 28 сессиясендә рәсми төстә сәламәтлекләрен какшата торган наркотик дип танылды. Аның халыкка зыян китерә торган йогынтысы сатыла торган исерткеч эчемлек күләменә бәйле рәвештә арта. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы экспертлары бәяләгәнчә, исерткеч эчемлекләр куллануның рөхсәт ителгән дәрәҗәсен арттыру (җан башына елына 8 литр абсолют алкоголь (сусыз спирт) Милләт сәламәтлеге өчен гаять куркыныч булып тора һәм әлеге чик һәр литрның ир-атларда 11 ай һәм хатын-кызларда 4 ай гомерен кыскарта. Дөньякүләм статистика нигезендә исерткеч эчемлек куллану 2 миллионга якын кешенең үлеменә китерә һәм бөтен дөньяда ел саен 4 проценты авырулар килеп чыгуга сәбәп булып тора.

Исерткеч эчемлекләрне чамадан тыш куллану демографик һәм социаль проблемаларның җыелуына сәбәп булып тора. Аларны чамадан тыш куллану кешеләрнең вакытыннан алда үлүеменә китерә һәм җәмгыятьнең билгеле бер өлешен социаль деградацияләүнең төп сәбәпләренең берсе булып тора, ул җинаятьчелек, көч куллану, ятимлек, сәламәтлек начараюга китерә, инвалидлык һәм суицид очраклары да шуннан чыгып арта бара. Шулай ук исерткеч эчемлекләрне күп куллану агуланып калуга гына түгел, ә бәлки үлемгә дә китерә. Үлемгә китерүнеэ сәбәпләре күп очракта бәхетсезлек, көчләү, йөрәк - кан тамырлары, онкология һәм башка чирләрдән килеп чыга, аны артык куллану явыз нияткә этәрә.

Тәмәке, шул исәптән тәмәке эшләнмәләре рәвешендә куллану халыкның сәламәтлегенә куркыныч яный. Тәмәке куллану һәм тәмәке төтене социаль, икътисади һәм экологик нәтиҗәләргә йогынтысы ясый.



Документ создан в электронной форме. № 298 от 26.02.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 7 из 24. Страница создана: 25.02.2026 11:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Яшьләр өчен исерткеч эчемлекләр, сыра һәм тәмәке куллануга каршы тору һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру өчен медицина профилактикасы кабинеты көчләре белән, табиб-наркологлар гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар өчен ел саен «Медицина белеме атнасы», «Балигъ булмаганнарны исерткеч эчемлекләренең зарарлы йогынтысыннан саклауда гаиләнең роле турында» ата-аналар конференцияләре үткәрелә. "Иллюзион» кинотеатрында ел саен укучы яшьләр өчен исерткеч эчемлекләр куллануны кисәтү буенча кинолекторий үткәрелә. Профилактик эш шулай ук шәһәрнең урта һөнәри оешмалары һәм югары уку йортлары укучылары һәм студентлары арасында видеофильм күрсәтелде «Эчкечелек, наркомания һәм тәмәке тартуның зыяны турында кисәтү» дигән темага үткәрелде. Җирле «Новая Кама» һәм «Алабуга Нуры» газеталарында эчкечелекне, тәмәке тартуны кисәтү һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча мәкаләләр бастырылды. Ел дәвамында уку йортларында, сәламәтлек саклау учреждениеләрендә, массакүләм яшьләр чараларында, «Исерткеч эчемлекләр организмга йогынтысы», «Балаларны гаиләдә наркотиклардан саклыйк» дигән белешмәлекләр таратылды.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Тәмәке продукциясен куллануны киметү чаралары турында» 2019 елның 3 сентябрендәге 1760 номерлы боерыгы нигезендә:

- дәвалау-профилактика учреждениеләренең барлык территорияләрендә һәм теләсә кайсы биналарында тәмәке тарту тыела;
- тәмәке әйберләрен дәвалау-профилактика учреждениеләре эчендә дә, аларның территорияләре чикләреннән 100 метрдан да кимрәк ераклыкта да ваклап сату тыела.

Барлык дәвалау-профилактика учреждениеләрендә тәмәке тарту өчен махсус билгеләнгән урыннарда темасына төсле аншлаглар урнаштырылган: Федераль закон нигезендә, «Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә тәмәке тарту тыела!».

«Алабуга үзәк район хастаханәсе» сәламәтлек саклау дәүләт автономияле учреждениесенең наркология бүлегендә даими рәвештә тәмәкегә бәйлелектән интегүче гражданнар өчен медицина ярдәме күрсәтү, тәмәке тартудан баш тартуда ярдәм итү һәм никотинның токсик йогынтысы нәтиҗәләрен төзәтү максатыннан бушлай консультатив кабул итү көннәре үткәрелә.

Матди-техник базаны яхшырту профилактик эшне камилләштерергә, сәламәт һәм имин яшәү рәвеше культурасын формалаштыру, шул исәптән алкоголь продукциясен һәм тәмәке куллануны профилактикалау буенча яңа формалар һәм ысуллар кертергә мөмкинлек бирәчәк.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, программа чаралары, көтелгән ахыргы нәтиҗәләрне тасвирлау, тормышка ашыру вакыты

Программаның төп максатлары булып: сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, культура дәрәҗәсен һәм сәламәтлек потенциалын күтәрү, вакытыннан алда



Документ создан в электронной форме. № 298 от 26.02.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 8 из 24. Страница создана: 25.02.2026 11:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

үлү очракларын кисәтү, сәламәт туклану исәбенә сәламәт яшәү рәвеше алып баручы гражданнарның өлешен арттыру, зарарлы гадәтләрдән, алкоголь һәм тәмәке кулланудан баш тарту. Сәламәт яшәүнең көтелгән дәвамлылыгын 67 яшькә кадәр арттыру тора.

Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

Сәламәт туклануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләү системасын формалаштыру;

Сәламәт туклануны, тәмәке төтененнән яклауны, алкоголь куллануны киметүне дә кертеп, гражданнарның сәламәт яшәү рәвеше алып баруына ярдәм итә торган мохит булдыру;

Мәгълүмат - коммуникация кампаниясе уздыру юлы белән гражданнарны сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивацияләү, шулай ук гражданнарны җәмәгать сәламәтлеген ныгыту чараларына җәлеп итү;

Халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәре өчен физик культура һәм спорт, массакүләм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, шул исәптән халыкның спорт объектлары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен арттыру;

Халкының уртача гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру.

Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча оештыру чаралары;

- иҗтимагый берләшмәләрне җәлеп итеп, ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең хезмәт коллективларында сәламәт яшәү рәвеше өчен хәрәкәт формалаштыру; - тәмәке тартмаучыларны һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баручыларны матди бүләкләү учреждениеләренең коллектив шартнамәләренә, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренә кертү;
- алкогольле эчемлекләр сату буенча сәүдә объектлары санын киметү;
- спортның абруен күтәрүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән чаралар, акцияләр үткәрү;
- яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, наркоманияне, алкоголизмны кисәтү, яшьләрнең сәламәтлеген яхшырту.

Программа чараларын гамәлгә ашыру физкультура һәм спорт өлкәсендә чараларны арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк.

Программа 2026-2028 елларда гамәлгә ашырыла.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетын формалаштыруны исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертергә (төгәлләш терелергә) тиеш.

(мең.сумнарда)

| Елы | Финанслауның чыгымнары |
| --- | --- |



Документ создан в электронной форме. № 298 от 26.02.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 9 из 24. Страница создана: 25.02.2026 11:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | Җирле бюджет | ТР бюджеты | Бюджеттан тыш | БАРЛЫГЫ |
|---|---|---|---|---|
| **2026** | 40 881,3 | 13 812,8 | 3,2 | 54 697,3 |
| **2027** | 42 460,3 | 14 539,8 | 3,2 | 57 003,3 |
| **2028** | 44 102,5 | 14 991,0 | 3,2 | 59 096,7 |
| **Барлыгы** | **127444,1** | **43 343,6** | **9,6** | **170 797,3** |

## IV. Программаны тормышка ашыру механизмы

**Программаны хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган: п**рограммада катнашучылар эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм координацияләү өчен җаваплы орган булып Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тора, ул «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесе белән килешү буенча берлектә түбәндәгеләрне башкара:

- программа чаралары исемлеген, аларны тормышка ашыру чыгымнарын, шулай ук Программаны гамәлгә ашыру механизмын ачыклау буенча тәкъдимнәр әзерли;
- максатчан индикаторлар исемлеген һәм аларны кварталлап бүлүне аныклый;
- программаны тормышка ашыру барышы турында хисап әзерли һәм аны законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшыра.

Хисап мәгълүматларын җыю һәм агрегацияләү буенча җаваплы булып - Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

Программаларны үтәүчеләр хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына Программа чараларының үтәлеше турында мәгълүмат тапшыралар.

## V. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге район халкының төрле төркемнәрендә авырулар саны кимүне, халык сәламәтлеген ныгытуны һәм тормыш сыйфатын күтәрүне, сәламәт яшәү рәвешенә, алкогольле продукция, сыра һәм тәмәке куллануны киметүгә юнәлтелгән профилактик чаралар белән халыкны тәэмин итүне күздә тота. Программаның максатчан индикаторларына һәм күрсәткечләренә уңышлы ирешүне тәэмин итү тиүбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- халыкның сәламәтлеген саклауга һәм яхшыртуга ярдәм итүче ведомствоара мөнәсәбәтләрнең яңа системасын булдыруга;
- халыкның сәламәтлеге дәрәҗәсен мониторинглауның нәтиҗәле



Документ создан в электронной форме. № 298 от 26.02.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 10 из 24. Страница создана: 25.02.2026 11:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

системасын булдыруга;

- кискен факторларны һәм авыруларны профилактикалау турында халыкка мәгълүмат бирү системасын көчәйтүгә;

- гражданнарның, иҗтимагый берләшмәләрнең, оешмаларның авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру белән бәйле инициативалары санын арттыруга;

- инвалидлык һәм мөнәсәбәтләрдәге киртәләрне бетерү, мөмкинлекләре чикләнгәннәргә шартлар булдыру, демографик вәзгыятьне яхшырту, уртача гомер озынлыгын арттыру, вакытыннан алда үлүчеләр санын киметү, авырулар санын киметү, халыкны инвалидлык өчен шартлар тудыруга.

Программаны гамәлгә ашыру кысаларында өстәмә рәвештә шәһәрдә һәм районда демографик вәзгыятьне яхшырту, вакытыннан алда үлүчеләр санын киметү, авырулар санын киметү, халыкны инвалидлык, уртача гомер озынлыгын арттыру тенденцияләрен өйрәнү планлаштырыла. Программаның максатчан индикаторларының һәм күрсәткечләренең әһәмияте түбәндәге таблицада китерелгән.

Бәяләү индикаторлары

| п/п | Программаның максатчан индикаторларының һәм күрсәткечләренең әһәмияте | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Программаның максатчан индикаторларының һәм күрсәткечләренең исеме | Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | | |
| | | **2026** | **2027** | **2028** |
| 1. | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы чаралар саны | 500 | 525 | 550 |
| 2. | Программа кысаларында чаралар белән колачланган халык өлеше | 45 | 50 | 55 |
| 3. | Сәламәт яшәү рәвеше өлкәсендә әзерләнгән белгечләр саны | 100 | 105 | 110 |
| 4. | Сәламәт яшәү рәвешен социаль рекламалау күләме (рекламаның бөтен күләменнән өлеше) | 12 | 13 | 14 |
| 5. | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыручы массакүләм мәгълүмат | 4,5 | 5 | 5,5 |



Документ создан в электронной форме. № 298 от 26.02.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 11 из 24. Страница создана: 25.02.2026 11:27
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | чараларында материаллар күләме (барлык мәгълүмат материалларының өлеше) | | | |

**2026-2028 елларга Алабуга муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү буенча муниципаль программасы чаралары**

| № т/б | Чаралар исеме | Үтәү вакыты (еллар) | Финанслау чыганаклары, (мең сумнарда) | | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Муниципаль бюджет | Республика бюджеты | Бюджеттан тыш чыганаклар | Барлыгы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| **«I.I. Сәламәт тукалануны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләү системасын формалаштыру».** | | **2026** | **40 881,30** | **13 812,80** | **1,0** | **54 695,10** | |
| | | **2027** | **42 460,30** | **14 539,80** | **1,0** | **57 001,10** | |
| | | **2028** | **44 102,50** | **14 991,00** | **1,0** | **59 094,50** | |
| 1.1. | Хезмәт коллективларында, ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә (оешмаларда) сәламәт яшәү рәвеше өчен хәрәкәт формалаштыру: | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | АМР Башкарма комитеты, Алабуга шәһәре (килешү буенча) Район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 1.2. | Психоактив матдәләрне профилактикалау өлкәсендә мәгълүмати-статистик база алып бару (балаларны ачыклау, исәпкә алу, күзәтү, "хәвеф-хәтәр төркеме" гаиләләре һ.б.) | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | «АМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 1.3. | Балалар һәм ата-аналар өчен уку программаларын кертү, белем бирү учреждениеләрендә наркотикларга каршы агарту һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча дәресләр үткәрүгә юнәлтелгән. | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | «АМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 1.4. | Психоактив матдәләрне профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвеше турында мәгълүмат материалларын гомуми белем бирү учреждениеләрендә бастыру. | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | «АМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 1.5. | Педагогик хезмәткәрләр өчен уртак технологияләр буенча өйрәтү семинар-тренинглары үткәрү. | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | «АМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ , АҮРХ ССДАУ (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 1.6. | Наркотикка бәйле авырулары булган кешеләрне реабилитацияләү мәсьәләләре буенча социаль юнәлешле коммерцияле булмаган берләшмәләр белән хезмәттәшлек. | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | АҮРХ ССДАУ (килешү буенча),җәмәгать оешмалары (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 1.7. | Социаль-куркыныч хәлдәге гаиләләр һәм куркыныч төркеменә кергән балигъ булмаганнар белән сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар үткәрү. | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | «Доверие-Ышаныч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексли үзәге» (килешү буенча),АҮРХ ССДАУ (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 1.8. | Психоактив матдәләрне профилактикалау буенча метафорик тренинглар курсларө үткәрү | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,5 | 0,5 | «Доверие-Ышаныч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексли үзәге (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,5 | 0,5 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,5 | 0.5 | |
| 1.9. | Наркотиклар турындагы белемнәрне тулыландыруга һәм аларга аңлы мөнәсәбәт булдыруга юнәлдерелгән «Сезнең тавыш» белемнәрне компьютерда сынау программасы буенча дәресләр үткәрү | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,5 | 0,5 | «Доверие-Ышаныч» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексли үзәге (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,5 | 0,5 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,5 | 0,5 | |

| № т/б | Чаралар исеме | Үтәү вакыты (еллар) | Финанслау чыганаклары, (мең сумнарда) | | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Муниципаль бюджет | Республика бюджеты | Бюджеттан тыш чыганаклар | Барлыгы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1.10. | Мәктәпкәчә мәгариф һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә балаларны рациональ (балансслы) тукландыруны оештыру<br>- барлык укучыларга, шул исәптән югары сыйныфларга, бушлай һәм (яки) ташламалы кайнар аш белән тәэмин итү;<br>- төрле комплекслар кулланып, укучыларның туклану рационын мәҗбүри витаминлаштыруны гамәлгә ашыру. | 2026 | 40 881,30 | 13 812,80 | 0,0 | 54 694,10 | «АМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 2027 | 42 460,30 | 14 539,80 | 0,0 | 57 000,10 | |
| | | 2028 | 44 102,50 | 14 991,00 | 0,0 | 59 093,50 | |
| 1.11. | Яшьләр арасында психоактив матдәләр куллануны мониторинглау (урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләре студентларын анкеталаштыру) | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | Уку йортлары |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 1.12. | Яшьләр арасында психоактив матдәләр куллануны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча мәгълүмати стендлар эшләү һәм аларны яшүсмерләр клубларында һәм яшьләр күпләп була торган урыннарда урнаштыру | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | АМРның «Барс» яшьләр үзәге МБУ (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| **II. Тәмәке әйберләре, алкоголь продукциясе һәм яшьләр арасында сыра куллануны профилактикалау;** | | **2026** | **0,0** | **0,0** | **2,2** | **2,20** | |
| | | **2027** | **0,0** | **0,0** | **2,2** | **2,20** | |
| | | **2028** | **0,0** | **0,0** | **2,2** | **2,20** | |
| 2.1. | Алабуга муниципаль районы территориясендә бердәм федераль балалар ышанычы телефоны ярдәмендә ашыгыч психологик телефон ярдәме күрсәтү | 2026 | 0,0 | 0,0 | **0.0** | 0,0 | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы “Психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм “Шанс” үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 2.2. | Мәгариф учреждениеләрендә, шәһәр урамнарында бердәм балалар ышаныч телефоны рекламасы | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы “Психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм “Шанс” үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 2.3. | Тәрбияләнүчеләр һәм «хәвеф-хәтәр төркеме» укучылары өчен сенсор җиһазлар кулланып коррекцион үстерү дәресләре үткәрү | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы “Психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм “Шанс” үзәге” муниципаль |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 2.4. | Ата-аналар һәм педагоглар өчен балаларны тәрбияләү, үстерү һәм укыту проблемалары буенча шәхси консультацияләр үткәрү | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы “Психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм “Шанс” үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 2.5. | «Хәвеф-хәтәр төркеме»әрбияләнүчеләре һәм укучылары өчен психоэмоциональ коррекция кабинеты җиһазларын кулланып, коррекцион-үстереш дәресләре үткәрү | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы “Психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм “Шанс” үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе (килешү буенча) |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| 2.6. | Ата-аналар җыелышлары кысаларында «Мәктәпкәчә яшьтә наркоманияне профилактикалау» темасына ата-аналар өчен семинарлар циклы | 2026 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | «АМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| | | 2027 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
| | | 2028 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | |
